# КАРАР

**26ноябрь 2021 ел** **№1**

## Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 25 ноябрендэ һәм 26 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлар, туендыручысын югалткан күп балалы (4 һәм аннан күбрәк) гаиләләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

-Каенсар авылында ике җәяүлеләр күперен төзекләндерү;

Каенсар авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

-Каенсар авылындагы Зеленая урамнарындагы юлларга вак таш җәю, таш салу,вак таш җәю,проект-смета документациясен эшләү,килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү һәм техник күзәтчелек

- Каенсар авылындагы Вокзал урамына асфальт җәю,асфальт сатып алу,ташу һәм җәю, килешү буенча эшләр очен түләү,смета һәм техник күзәтү очен түләү,экспертиза.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

2021 елның 25 һәм 26 ноябренә торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны – 394 кеше.

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 271 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 160 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 160 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегендә халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлар, күп балалы гаиләләр һәм туендыручысын югалткан гаиләләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә :

-Каенсар авылында ике җәяүлеләр күперен төзекләндерү;

Каенсар авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

-Каенсар авылындагы ,Зеленая урамнарындагы юлларга вак таш җәю, таш салу,вак таш җәю,проект-смета документациясен эшләү,килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү һәм техник күзәтчелек;

- Каенсар авылындагы Вокзал урамына асфальт җәю,асфальт сатып алу,ташу һәм җәю, килешү буенча эшләр очен түләү,смета һәм техник күзәтү очен түләү,экспертиза.

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Каенсар авыл җирлеге башлыгы И.А.Мифтахов